Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 8-31 номерлы карары

**Казан шәһәре Думасының**
**2015 елның 3 августындагы 19-44 номерлы**
**«“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитетының Куллanучылар базары комитеты”**
**муниципаль казна учреждениесе турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Гражданлык кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлкәсендә идарә функцияләрен башкару өлкәсендә вәкаләтләрне камилләштерү максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2015 елның 3 августындагы 19-44 номерлы карары (Казан шәһәре Думасының 2016 елның 16 сентябрендәге 13-10 номерлы, 2017 елның 25 февралендәге 22-13 номерлы, 2017 елның 15 ноябрендәге 10-21 номерлы, 2019 елның 26 февралендәге 9-32 номерлы, 2022 елның 3 августындагы 21-15 номерлы, 2023 елның 14 июнендәге 5-23 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. III бүлектә:

1.1.1. 3.1.8 пунктчаны «дәүләт хакимияте» сүзләреннән соң «органнары» сүзе белән тулыландырырга;

1.1.2. 3.1.20.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1.20.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән каралган очракларда хуҗалык итүче субъектларга билгеләнгән таләпләр нигезендә компенсация (буш) урыннары бирү тәртибен эшләү»;

1.1.3. 3.1.32 пунктчада «инвентаризация» сүзен «исәпкә алу» сүзенә

алмаштырырга;

1.1.4. 3.1.37 пунктчаны «Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вакыт эчендә» сүзләре белән тулыландырырга;

1.1.5. 3.1.42 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1.42. Казан шәһәренең мобилизация әзерлеге чараларында катнашу һәм мобилизация буенча билгеләнгән йөкләмәләрнең үтәлешен тәэмин итү максатыннан Комитетны мобилизация ягыннан әзерләүне гамәлгә ашыру, шул исәптән: хәрби чорда эшләү өчен Казан шәһәре территориясендә сәүдә торышының төп күрсәткечләренә фаразлау рәвешендә анализ ясау; Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кертелгән очракта, Казан шәһәре халкын нормалаштырылган тәэмин итүне планлаштыру, әзерләү һәм оештыру; нормалаштырылган тәэмин итү системасына кертү өчен шәһәр территориясендә күпләп (ваклап) сатуны гамәлгә ашыра торган хуҗалык итүче субъектлар һәм аларның сәүдә объектлары эшчәнлеген мониторинглау; оешмалар белән мобилизация буенча йөкләмәләрне (заказларны) үтәү турында шартнамәләр (контрактлар) төзү; запаста булган һәм Комитетта эшләүче гражданнарны мобилизация чорында һәм хәрби чорда хәрби исәпкә алу һәм броньлау эшләрен башкару»;

1.1.6. түбәндәге эчтәлекле 3.1.46 пунктча белән тулыландырырга:

«3.1.46. оператив идарә итү хокукында Комитетка беркетелгән торак булмаган биналарны милекче ризалыгы белән арендага һәм бушлай файдалануга бирү»;

1.1.7. 3.1.46 пунктчаны 3.1.47 пунктча дип санарга;

1.2. V бүлекнең 5.3 пунктын «һәм әлеге милек белән милекче ризалыгыннан чыгып эш итү» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитетына (Р.Ф.Фазылҗанов) әлеге карар нигезендә Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**